Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Бикчурай торак пунктында гражданнар җыены

# КАРАРЫ

21 ноябрь 2025 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Зур Мәшләк һәм Югары Мәшләк торак пунктларында гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга.

2. Бикчурай торак пунктында территориясендә:

- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- рөхсәтсез барлыкка китерелгән чүплекләрне юк итү.

3.Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы,50А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: М.М.Шәмсевәлиев

Зур Мәшләк авыл җирлеге
Башлыгы М.М.Шәмсевәлиев